МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

24.07.2017 Казан ш. № 8-05-4/134

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибе турында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары– министр Р.А.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының 24.07.2017 ел №8-05-п/134 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде.

Бу Тәртип Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык кооперативы, бакчачылык куллану кооперативы, күчемсез милек милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциясез оешма) белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибе процедурасын җайга сала.

Бу Тәртип үзләре өчен эшкә яллаучы вәкиле булып Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры торган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү турында гариза (алга таба – Гариза) гражданлык хезмәткәре тарафыннан бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге форма буенча язмача төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка (алга таба - Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны, кергән көнне, бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча буенча, Журналда терки.

5. Җаваплы зат гаризаны башлангыч төстә карап тикшерә һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Җаваплы зат Гаризаны башлангыч төстә карап тикшерү барышында

Гаризаны тапшырган гражданлык хезмәткәреннән коммерциясез оешма белән күздә тотылган идарә итүдә катнашу буенча функцияләрне билгеләүче документлар һәм язмача аңлатмалар соратып алуга хокуклы.

Бәяләмә гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү яки ризалык бирүдән баш тарту турында тәкъдимнән торырга тиеш.

6. Җаваплы зат Гаризаны теркәүгә алганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Бәяләмә һәм башка материаллар (булганда) белән, дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү яки ризалык бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен, Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрына (аның бурычларын башкаручы затка) тапшыра.

Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткәннән соң ике эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа, министр резолюциясе белән, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге мөһере белән расланган Гариза күчермәсен, имза куйдыртып, тапшыра. Гаризаның төп нөсхәсе, министр резолюциясе белән, гражданлык хезмәткәренең шәхси делосына теркәп куела.

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибенә №1 кушымта

Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрына

________________________________

________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфасы һәм структур
_______________________________
подразделение, яшәү урыны адресы
_______________________________
телефон номеры)

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү турында

ГАРИЗА

Миңа идарә итүдә катнашырга, коллегиаль идарә органы составына керергә рөхсәт бирүегезне сорыйм (кирәклесенең астына сызарга)________________________________________________________________
(иҗтимагый оешма,
________________________________________________________________
торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык кооперативы,
________________________________________________________________
бакчачылык куллану кооперативы, күчемсез милек милекчеләре ширкәте атамасы)
бушлай нигездә, түбәндәге сыйфатта ________________________________________________________________
(бер генә башкарма орган яки коллегиаль идарә органы
________________________________________________________________
атамасы).

___________ _________________ _____________________________
(дата) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү тәртибенә №2 кушымта

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән бер генә башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә ризалык бирү турында гаризаларны теркәү

| № п/п | Дата | Үтенечнамә тапшыручының Ф.И.О., вазыйфасы | Үтенечнамә тапшыручы имзасы | Теркәүгә алучының Ф.И.О. | Теркәүгә алучының имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |